ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

_______________ с. Нижний Услон _______________

71                29.10

Гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге генераль планы проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

3.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 2018 елның 20 ноябрендә, 10.00 сәгатьтә Түбән Ослан авылы мәдәният йортында;

3.2. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2018 елның 21 ноябрендә, 10.00 сәгатьтә Воробьевка авылында часовня янында;

3.3. Үткәрү вакыты - берәр көн;

3.4. Фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә мөмкин булган адрес - Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Л.В. Чемодановага (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 гә кадәр) чыгышы хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирергә мөмкин.

3.5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 2018 елның 19 ноябренә кадәр (тел 8437930-5-44)

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы

Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А. З. Шәйдуллин